2022 елдан башлап һәр елны Татарстан Республикасы бюджетына «Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондының уставы нигезендә эшчәнлеген башкаруы өчен кирәкле акча салуны күздә тотарга;

Фондны гамәлгә куючы тарафыннан ирекле мөлкәти кертем буларак Фондка тапшырыла торган Татарстан Республикасы мөлкәте составын билгеләүне тәэмин итәргә;

Фондны Казан шәһәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Россия Федерациясе законнары нигезендә «Игелек –

Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондын дәүләт теркәвенә алу һәм аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарларны кабул итүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 03 февраль
№ ПУ-85

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 03 » февралендәге
ПУ-85 номерлы Указына
1 нче кушымта

**«Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фонды уставы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фонды (алга таба – Фонд) – Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан социаль һәм иҗтимагый файдалы максатларга ирешү өчен оештыру-хокукый рәвеше фонд буларак гамәлгә куелган, анда әгъзалык каралмаган унитар коммерциячел булмаган оешма.

1.2. Татарстан Республикасы исеменнән Фондны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Гамәлгә куючы) башкара.

1.3. Фондның рус телендә тулы рәсми атамасы – Республиканский фонд содействия духовно-нравственному развитию общества «Игелек-Доброта».

Фондның рус телендә кыскартылган рәсми атамасы – Фонд «Игелек – Доброта».

Фондның татар телендә тулы рәсми атамасы – «Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фонды.

Фондның татар телендә кыскартылган рәсми атамасы – «Игелек – Доброта» фонды.

1.4. Үз эшчәнлегендә Фонд Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Уставка таяна.

1.5. Федераль законда каралган тәртиптә дәүләт теркәве узган көннән фонд юридик зат була, милкендә аерым мөлкәте була, үз исеменнән мөлкәти

һәм мөлкәти булмаган хокуклар алу һәм аларны гамәлгә ашыру, йөкләмәләр үтәү, судта дәгъва кылучы һәм җавап тотучы булу хокукы ала.

1.6. Фонд үз йөкләмәләре буенча, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәгъва кылу мөмкин булмаган мөлкәттән тыш, барлык мөлкәте белән җавап бирә.

1.7. Федераль законнарда каралган очраклардан тыш, Гамәлгә куючы Фонд йөкләмәләре өчен, ә Фонд Гамәлгә куючы йөкләмәләре өчен җавап тотмый.

1.8. Фондның үз балансы була. Фонд Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә билгеле тәртиптә кредит оешмаларында, валюта счетларын да кертеп, исәп-хисап һәм башка счетлар ачу хокукына ия.

1.9. Фондның үз атамасы язылган түгәрәк мөһере, штамплары һәм бланклары, шулай ук эмблема рәвешендә символикасы бар.

Эмблема биш таҗ яфракчыклы лалә чәчәге ясалган түгәрәк тәңкә рәвешендә. Таҗ яфракчыклары мәчет гөмбәзе рәвешен хәтерләтә. Өстәге таҗ яфракчыкларының эчке сызык-сурәте шулай ук очлаеп килгән аркалы гөмбәзләр рәвешендә эшләнгән.

Эмблеманың уртасында гарәп хәрефләрен кертеп «Игелек» сүзе язылган, аскы өлештә – 2022 – Фондны оештыру елы күрсәтелгән. Аскы өлештә уртада өч таҗ яфракчыклы лалә чәчәгенең стильләштерелгән сурәте урнаштырылган.

Тәңкә сурәте өстендә көнбатыш стильдә – «Игелек» сүзе, тәңкә сурәте астында «Доброта» сүзе урнаштырылган.

1.10. Фонд эшчәнлеге вакытын чикләмичә төзелә.

1.11. Россия Федерациясе законнары нигезендә Фонд Россия Федерациясе территориясендә филиалларын булдырырга һәм вәкиллекләрен ачарга хокуклы.

Фондның филиаллары һәм вәкиллекләре турындагы белешмәләр Фондның Уставында күрсәтелә һәм алар Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелергә тиеш.

1.12. Фонд урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре.

## II. Фондның максатлары һәм эшчәнлеге предметы

2.1. Фонд эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләр:

җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү, иҗтимагый мирасны баету, Татарстан Республикасы халыкларының йолаларын һәм гореф-гадәтләрен саклау;

Татарстан Республикасының фәнни, мәдәни, интеллектуаль һәм туристлык мөмкинлекләрен үстерү.

2.2. Фондның эшчәнлеге түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән:

җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсеше өчен кирәкле объектларны (алга таба шулай ук – Объектлар) төзү, торгызу һәм яңартып кору, аларны куллану

һәм карап тоту, шулай ук Объектлар янындагы территорияләрне төзекләндерү һәм үстерү белән бәйле чараларны финанслау;

билгеләнгән таләпләр нигезендә Объектларны саклауны һәм карап тотуны тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү;

Фонд эшчәнлегенең максатлары нигезендә үз программаларын һәм чараларын, шулай ук башка оешмалар, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә эшләнгән программаларны һәм чараларны гамәлгә ашыру;

шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү;

хәйрия эшчәнлеге;

Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә күргәзмә, нәшрият эшчәнлеген башкару, шул исәптән басмалар, кино-, теле-, видео- һәм аудиопродукция чыгару;

Фонд эшчәнлеге максатларын үтәү өчен ил һәм чит илләр инвестицияләрен, кредитларын, заемнарны һәм башка ресурсларны җәлеп итү;

Фондның вакытлыча кулланылышта булмаган акчасын инвестиция буларак тоту;

Фондның күчемсез милкенә, шул исәптән җир кишәрлекләренә идарә итү;

Фонд эшчәнлеге максатларын үтәү өчен мәгълүмат системаларын булдыру һәм эшләтү.

## III. Фондның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Фонд түбәндәгеләргә хокуклы:

акчалата һәм башка рәвешләрдә мөлкәт алырга;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Фондның әлеге Устав нигезендә эшчәнлек предметына кертелгән барлык эшчәнлек төрләрен башкарырга;

Россия Федерациясе законнары нигезендә махсус рөхсәт алу (лицензия, аккредитация узу турында белешмә, башка рөхсәт кәгазьләре) таләп ителгән эшчәнлекне тиешле рөхсәт нигезендә башкарырга;

шартнамәләр төзергә, мөлкәт алырга, юридик һәм физик затлар белән башка төрле гражданлык-хокук мөнәсәбәтләрен урнаштырырга;

Фонд эшчәнлеге максатларына туры килә торган һәм үзе шулар хакына төзелгән социаль һәм җәмгыять өчен файдалы максатларга ирешү өчен кирәкле эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

законнарда билгеләнгән тәртиптә хуҗалык җәмгыятьләре төзергә һәм (яки) аларда катнашырга;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Фондның милке булган мөлкәткә, шул исәптән җир кишәрлекләрен дә кертеп, ия булырга, файдаланырга һәм аның белән бәйле гамәлләр кылырга;

әлеге Уставның 2.1 пунктында каралган социаль һәм җәмгыять өчен файдалы максатларга ирешү һәм Фондның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Фондның мөлкәтен сатудан һәм башка эшчәнлектән алынган керемне файдаланырга;

кертем буларак акча салырга;

Фонд эшчәнлегенең максатларын үтәүгә кредит ресурслары табарга һәм аларны тотарга;

үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча, шул исәптән килешүләр төзү юлы белән дә, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, барлык милек рәвешендәге оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә;

Фондның әлеге Уставта каралган эшчәнлеген башкару өчен кирәкле консультация комитетлары, комиссияләр, эш төркемнәре төзергә;

Фонд эшчәнлеге максатларына ирешү өчен Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка хокуклардан файдаланырга.

3.2. Фондның бурычлары:

Фонд эшчәнлеге максатларына ирешү өчен Фондка бирелгән финанс тәэминатын, шулай ук Фондның устав эшчәнлеге кысаларында кергән башка акчаны максатчан куллануны тәэмин итәргә;

Фонд милкендәге мөлкәтнең тиешенчә саклануын һәм максатчан файдаланылуын тәэмин итәргә, шулай ук әлеге мөлкәтнең файдаланылуы турында ел саен хисап бастырып чыгарырга;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кредит оешмаларында счетлар ачарга;

Фонд урнашкан җирдә даими сакланырга тиешле документларның саклануын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә аларның дәүләт саклавына тапшырылуын тәэмин итәргә;

Фондның гамәлгә кую турындагы документларының, боерыкларының, Фонд органнарының утырышлары беркетмәләренең һәм Фондның башка документларының саклануын тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Уставта каралган башка бурычларны үтәргә.

## IV. Фондның мөлкәте

4.1. Төзелгән вакытта Фондка Гамәлгә куючысы тарафыннан тапшырылган яисә аның тарафыннан эшчәнлеге барышында сатып алынган мөлкәт Фондның милке була. Гамәлгә куючы үзе Фонд милкенә тапшырган мөлкәткә милек хокукын югалта.

4.2.Фондның мөлкәтен булдыру чыганагы түбәндәгеләр:

Гамәл куючыдан даими яисә бер тапкыр тапшырылган керем;

ирекле рәвештә бирелгән мөлкәти кертемнәр һәм хәйрия керемнәре;

товарлар сатудан, эшләрдән, хезмәт күрсәтүдән алынган керем;

акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр һәм кертемнәрдән алынган дивидентлар (керемнәр, процентлар);

Фонд милкеннән алына торган керемнәр;

законнарда тыелмаган башка керемнәр.

4.3. Фонд үз мөлкәтен Фонд эшчәнлеге максатларына ирешү өчен файдалана.

4.4. Фонд аның милкендәге һәм башка төрле хокуктагы мөлкәте белән бәйле Россия Федерациясе законнарына һәм әлеге Уставка каршы килми торган теләсә-нинди эш йөртә ала.

4.5. Фонд тарафыннан булдырылган, сатып алынган яисә гражданнар яки оешмалар тарафыннан тапшырылган мөлкәт, акча, акцияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр, интеллектуаль милеккә хокукларны да кертеп, аның милке булып тора.

4.6. Фондның барлык мөлкәте, аның эшчәнлегеннән алынган керем Фондның милке була. Фонд үз мөлкәтенә аның билгеләнешенә туры китереп һәм уставта каралган максатларга ирешү өчен генә ия була, аннан файдалана һәм аңа бәйле эш йөртә.

4.7. Фонд акчасын тоту Фондның Күзәтчелек советы тарафыннан расланган смета чикләрендә башкарыла.

## V. Фондны гамәлгә куючы

5.1. Гамәлгә куючы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итәргә вәкаләтле:

Фондның Күзәтчелек советы составы, Фондның Попечительләр советы составы, Фондның Ревизия комиссиясе составы яисә ревизор кандидатурасы буенча, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү;

Фондның Башкарма директоры кандидатурасына кагылышлы тәкъдимнәр әзерләү;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Фондның башкарма директоры белән хезмәт килешүен төзү, аңа үзгәреш кертү, аның гамәлен туктату;

5.2. Гамәлгә куючы федераль законнар, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары һәм әлеге Устав нигезендә башка функцияләр башкара һәм вәкаләтләргә ия була.

## VI. Фондның органнары

6.1. Фонд органнары түбәндәгеләр:

Фондның Күзәтчелек советы – Фондка идарә итүнең иң югары коллегиаль органы;

Фондның Попечительләр советы – Фондның эшчәнлегенә күзәтчелек итүче орган;

Фондның башкарма директоры – Фондның бер генә кешедән торган башкарма органы;

Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) – Фондның контроль-ревизия органы.

6.2. Фондның Күзәтчелек советы составы кимендә 15 (унбиш) әгъзадан оештырыла һәм Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 5 (биш) елга раслана. Фондның Күзәтчелек советы эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыра.

6.3. Фондның Күзәтчелек советының махсус вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Фонд эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, аның мөлкәтен булдыру һәм файдалану принципларын билгеләү;

Фондның Уставына кертелә торган үзгәрешләрне раслау;

Фонд органнарын төзү һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

еллык хисапларны һәм Фондның еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын раслау;

Фонд тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләре төзү һәм (яисә) Фондның аларда катнашуы турындагы карарлар кабул итү;

филиаллар төзү һәм (яисә) Фонд вәкиллекләрен ачу турындагы карарлар, шулай ук алар турында нигезләмәләр кабул итү;

законнарда каралган очракларда Фонд тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләрне хуплау;

Фондның Күзәтчелек советы, Фондның Попечительләр советы, Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) турындагы нигезләмәләрне раслау;

Фондның Башкарма директорын вазыйфага сайлау һәм вазыйфадан азат итү;

Фондның аудиторлык оешмасын яисә хосусый аудиторын, аларга түләү күләмен раслау;

Фонд гамәлгә ашыра торган программаларны финанслау чаралары планын раслау;

Фонд планнарын, керемнәр һәм чыгымнар сметаларын карап тикшерү, расланган программаларны гамәлгә ашыру турындагы хисапларны раслау;

Фондның идарә аппаратына тотыла торган чыгымнар һәм хуҗалыкның эчке чыгымнары нормативларын билгеләү;

Фонд структурасын раслау;

Фондны бетерү турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул итү;

Фондның әлеге Уставта каралган эшчәнлеген башкару өчен кирәкле консультация комитетлары, комиссияләр, эш төркемнәре төзү;

Фондка идарә итүнең югары коллегиаль органының законнар тарафыннан махсус вәкаләтенә кертелгән башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

6.4. Фондның Күзәтчелек советы үз эшчәнлеген нигездә утырышлар рәвешендә алып бара.

Фондның Күзәтчелек советы әгъзалары утырышта видео-конференц-элемтәдән кулланып читтән торып катнаша ала.

6.5. Фондның Күзәтчелек советы карары читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

6.6. Әлеге Уставның 6.3 пунктындагы икенче – сигезенче, унынчы, унберенче, уналтынчы абзацларында каралган мәсьәләләр буенча карарлар кабул иткәндә читтән торып тавыш бирү уздырылмый.

6.7. Фондның Күзәтчелек советы утырышы яисә аның әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе, әгәр утырышта яисә читтән торып тавыш бирүдә Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, эш йөртергә хокуклы була.

6.8. Фондның Күзәтчелек советының махсус компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча карарлары Фондның Күзәтчелек советының утырышта яисә читтән торып тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының өчтән ике өлешеннән ким булмаган квалификацияле күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Фондның Күзәтчелек советының махсус компетенциясенә кагылмаган башка мәсьәләләр буенча карарлары Фондның Күзәтчелек советының утырышта яисә читтән торып тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Фондның Күзәтчелек советының карарларын кабул иткәндә аның һәр әгъзасы бер тавышка ия була. Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының тавышлары тигез санда булганда, Фондның Күзәтчелек советы рәисенең тавышы хәлиткеч була.

6.9. Фондның Күзәтчелек советы утырышы яисә аның әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе Фондның Күзәтчелек советы рәисе карары нигезендә ихтыяҗ туган саен, әмма ким дигәндә ярты елга бер тапкыр уздырыла.

6.10. Фондның Попечительләр советының яки Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының кимендә яртысының яки Фондның Ревизия комиссиясенең (ревизорның) язма таләбе буенча Фондның Күзәтчелек советы рәисе тарафыннан Фондның Күзәтчелек советының чираттан тыш утырышы чакырыла.

6.11. Фондның Күзәтчелек советы рәисе Фондның Күзәтчелек советы утырышларын ача, алып бара һәм аларда рәислек итә. Фондның Күзәтчелек советы рәисе утырышта булмаганда, Фондның Күзәтчелек советы рәисе күрсәтмәсе нигезендә аның вазыйфаларын урынбасарларының берсе башкара.

6.12. Фондның Күзәтчелек советы утырышларын уздыру тәртибе Фондның Күзәтчелек советы турындагы нигезләмәгә таянып билгеләнә.

6.13. Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен оештыру турындагы карар Фондның Күзәтчелек советы рәисе тарафыннан кабул ителә, ул көн тәртибен, тавыш бирү процедурасының тәмамлану вакытын, Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына хәбәр бирү тәртибен, Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына бирелергә тиешле

мәгълүмат исемлеген, читтән торып тавыш бирүне уздыру белән бәйле башка мәсьәләләрне хәл итүне билгели.

6.14. Читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәр Фондның Күзәтчелек советының һәрбер әгъзасына тавыш бирү процедурасы тәмамлану көненә кимендә 15 (унбиш) календарь көн кала җибәрелергә тиеш. Фондның Күзәтчелек советының әгъзалары Фондның Күзәтчелек советы рәисенә көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турындагы тәкъдимнәр юлларга мөмкин.

6.15. Читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәрдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

көн тәртибе;

читтән торып тавыш бирү башланганчы Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына тапшырылырга тиешле мәгълүмат (материаллар) белән танышу тәртибе һәм аның белән танышырга мөмкин булган адрес;

тавыш бирү процедурасы тәмамлану вакыты;

Фондның Күзәтчелек советы әгъзасы тавыш бирү бюллетене (бюллетеньнәре) җибәрү адресы;

законнарда һәм Фондның эчке документларында каралган башка мәгълүматлар.

6.16. Көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертелгән очракта, Фондның Күзәтчелек советының һәрбер әгъзасына үзгәртелгән көн тәртибе юллана.

6.17. Читтән торып тавыш бирүне уздыру турындагы хәбәр көн тәртибе мәсьәләләре буенча әлеге Уставның 6.15 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат булган тавыш бирү бюллетеньнәре җибәрү юлы белән дә башкарылырга мөмкин.

6.18. Фондның Күзәтчелек советының һәрбер әгъзасының көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары кертелгән тавыш бирү бюллетеньнәре Фондка юллана. Тавыш бирү бюллетеньнәре шулай ук Фонд вәкиленә шәхсән кул куйдырып тапшырылырга мөмкин.

6.19. Читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының тавыш бирүе турындагы мәгълүмат кертелгән документлар кабул итүнең ахыргы көненнән соңгы көн;

тавыш бирүдә катнашкан затлар турындагы белешмәләр;

көн тәртибенең һәр мәсьәләсе буенча тавыш бирү йомгаклары;

тавышларны санаган затлар турында белешмәләр;

беркетмәгә кул куйган затлар турында белешмәләр.

6.20. Фондның Күзәтчелек советының эшчәнлегенә Фондның Күзәтчелек советы рәисе җитәкчелек итә. Фондның Күзәтчелек советы рәисе Фондның Күзәтчелек советы эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыруны һәм аның Фондның башка органнары белән хезмәттәшлеген тәэмин итә.

6.21. Фондның Күзәтчелек советы рәисе:

Фондның Күзәтчелек советы эшен оештыра;

Фондның Күзәтчелек советы утырышлары планын эшләүне оештыра;

Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына Фондның Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе мәсьәләләре яки Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү мәсьәләләре буенча карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматның вакытында тапшырылуын тәэмин итә;

Фондның Күзәтчелек советы утырышларын җыя һәм аларда рәислек итә яисә Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен оештыра;

Фондның әлеге Уставында һәм башка эчке документларында каралган, Фондның башка органнары вәкаләтләренә керми торган вәкаләтләрне башкара.

6.22. Фондның Күзәтчелек советы үз составыннан Фондның Күзәтчелек советы секретарен 5 (биш) елга сайлый. Фондның Күзәтчелек советы секретаре турыдан-туры Фондның Күзәтчелек советы рәисенә буйсына.

6.23. Фондның Күзәтчелек советы секретаре:

Фондның Күзәтчелек советы утырышларын уздыру яисә Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен уздыру турында Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына алдан ук хәбәр бирә;

Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына Фондның Күзәтчелек советы утырышларына, Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүенә кирәкле мәгълүматны һәм материалларны юллый;

Фондның Күзәтчелек советы утырышы, Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе көн тәртибенә мәсьәләләр әзерләгәндә Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларына техник һәм оештыру ягыннан ярдәм күрсәтә;

Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының тавышларын санауны алып бара;

Фондның Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләрен һәм Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне алып бара һәм тутыра;

Фондның Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләреннән, Фондның Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдән өземтәләр ясый һәм аларны үз имзасы белән раслый;

Фондның Күзәтчелек советына килгән документларны һәм аннан җибәрелгән документларның күчермәләрен исәптә тотуны, саклауны башкара.

6.24. Фондның Попечительләр советы составы кимендә 5 (биш) әгъзадан оештырыла һәм Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 5 (биш) елга раслана. Фондның Попечительләр советы эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыра.

6.25. Фондның Попечительләр советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Фондның эшчәнлегенә, Фондның башка органнарының карарлар кабул итүенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүенә, Фонд акчаларын тотуга, Фондның законнарны үтәвенә күзәтчелек итү;

Фондның Күзәтчелек советына түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертү:

җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсеше өчен кирәкле объектлар төзү, торгызу һәм яңартып кору белән бәйле чараларны финанслау;

җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсеше өчен кирәкле объектлар янындагы территорияләрне төзекләндерү һәм үстерү;

төрле күргәзмә, нәшрият чараларын, шул исәптән басмалар, кино-, теле-, видео- һәм аудиопродукция чыгару белән бәйле чаралар уздыру;

Фондның күчемсез милкенә, шул исәптән җир кишәрлекләренә, идарә итү;

Фонд эшчәнлегенең максатлары нигезендә үз программаларын һәм чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук башка оешмалар, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә эшләнгән программаларны һәм чараларны гамәлгә ашыру;

әлеге Уставта каралган эшчәнлеген башкару өчен кирәкле консультация комитетлары, комиссияләр, эш төркемнәре төзү.

6.26. Фондның Попечительләр советы үз эшчәнлеген нигездә утырышлар рәвешендә алып бара.

Фондның Попечительләр советы әгъзалары утырышта видеоконференц-элемтәдән кулланып читтән торып катнаша ала.

6.27. Фондның Попечительләр советы карары читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

6.28. Фондның Попечительләр советы утырышы яисә аның әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе, әгәр утырышта яисә читтән торып тавыш бирүдә Фондның Попечительләр советы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, эш йөртергә хокуклы була.

6.29. Фондның Попечительләр советы карарлары Фондның Попечительләр советының утырышта яисә читтән торып тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Фондның Попечительләр советы карарларын кабул иткәндә аның һәр әгъзасы бер тавышка ия була. Фондның Попечительләр советы әгъзаларының тавышлары тигез санда булганда, Фондның Попечительләр советы рәисенең тавышы хәлиткеч була.

6.30. Фондның Попечительләр советы утырышы яисә аның әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе Фондның Попечительләр советы рәисе карары нигезендә ихтыяҗ туган саен, әмма ким дигәндә ярты елга бер тапкыр уздырыла.

6.31. Гамәлгә куючының яисә Фондның Попечительләр советы әгъзаларының кимендә яртысының яки Фондның Ревизия комиссиясенең (ревизорның) язма таләбе буенча Фондның Попечительләр советы рәисе

тарафыннан Фондның Попечительләр советының чираттан тыш утырышы чакырыла.

6.32. Фондның Попечительләр советы рәисе Фондның Попечительләр советы утырышларын ача, алып бара һәм аларда рәислек итә. Фондның Попечительләр советы рәисе утырышта булмаганда, аның вазыйфаларын Фондның Попечительләр советы әгъзаларының әлеге утырышта сайлап куелган берсе башкара.

6.33. Фондның Попечительләр советы утырышларын уздыру тәртибе Фондның Попечительләр советы турындагы нигезләмәгә таянып билгеләнә.

6.34. Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен оештыру турындагы карар Фондның Попечительләр советы рәисе тарафыннан кабул ителә, ул көн тәртибен, тавыш бирү процедурасының тәмамлану вакытын, Фондның Попечительләр советы әгъзаларына хәбәр бирү тәртибен, Фондның Попечительләр советы әгъзаларына бирелергә тиешле мәгълүмат исемлеген, читтән торып тавыш бирүне уздыру белән бәйле башка мәсьәләләрне хәл итүне билгели.

6.35. Читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәр Фондның Попечительләр советының һәрбер әгъзасына тавыш бирү процедурасы тәмамлану көненә кимендә 15 (унбиш) календарь көн кала җибәрелергә тиеш. Фондның Попечительләр советы әгъзалары Фондның Попечительләр советы рәисенә көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турындагы тәкъдимнәр юлларга мөмкин.

6.36. Читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәрдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

көн тәртибе;

читтән торып тавыш бирү башланганчы Фондның Попечительләр советы әгъзаларына тапшырылырга тиешле мәгълүмат (материаллар) белән танышу тәртибе һәм аның белән танышырга мөмкин булган адрес;

тавыш бирү процедурасы тәмамлану вакыты;

Фондның Попечительләр советы әгъзасы тавыш бирү бюллетене (бюллетеньнәре) җибәрү адресы;

законнарда һәм Фондның эчке документларында каралган башка мәгълүматлар.

6.37. Көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертелгән очракта, Фондның Попечительләр советының һәрбер әгъзасына үзгәртелгән көн тәртибе юллана.

6.38. Читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәр көн тәртибе мәсьәләләре буенча әлеге Уставның 6.36 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат кертелгән тавыш бирү бюллетеньнәре җибәрү юлы белән дә башкарылырга мөмкин.

6.39. Фондның Попечительләр советының һәрбер әгъзасының көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары кертелгән тавыш бирү бюллетеньнәре Фондка юллана.

6.40. Читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

Фондның Попечительләр советы әгъзаларының тавыш бирүе турындагы мәгълүмат кертелгән документларны кабул итүнең ахыргы көненнән соңгы көн;

тавыш бирүдә катнашкан затлар турындагы белешмәләр;

көн тәртибенең һәр мәсьәләсе буенча тавыш бирү йомгаклары;

тавышларны санаган затлар турында белешмәләр;

беркетмәгә кул куйган затлар турында белешмәләр.

6.41. Фондның Попечительләр советы эшчәнлегенә Фондның Попечительләр советы рәисе җитәкчелек итә. Фондның Попечительләр советы рәисе Фондның Попечительләр советы эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыруны һәм аның Фондның башка органнары белән хезмәттәшлеген тәэмин итә.

6.42. Фондның Попечительләр советы рәисе:

Фондның Попечительләр советы эшен оештыра;

Фондның Попечительләр советы утырышлары планын эшләүне оештыра;

Фондның Попечительләр советы әгъзаларына Фондның Попечительләр советы утырышының көн тәртибе мәсьәләләре яки Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү мәсьәләләре буенча карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматның вакытында тапшырылуын тәэмин итә;

Фондның Попечительләр советы утырышларын җыя, аларда рәислек итә яисә Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен оештыра;

Фондның әлеге Уставында һәм башка эчке документларында каралган, Фондның башка органнары вәкаләтләренә керми торган башка вәкаләтләрен башкара.

6.43. Фондның Попечительләр советы үз составыннан Фондның Попечительләр советы секретарен 5 (биш) елга сайлый. Фондның Попечительләр советы секретаре турыдан-туры Фондның Попечительләр советы рәисенә буйсына.

6.44. Фондның Попечительләр советы секретаре:

Фондның Попечительләр советы утырышларын уздыру яисә Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүен уздыру турында Фондның Попечительләр советы әгъзаларына алдан ук хәбәр бирә;

Фондның Попечительләр советы әгъзаларына Фондның Попечительләр советы утырышларына, Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүенә кирәкле мәгълүматны һәм материалларны юллый;

Фондның Попечительләр советы утырышларына, Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе көн

тәртибенә мәсьәләләр әзерләгәндә Фондның Попечительләр советы әгъзаларына техник һәм оештыру ягыннан ярдәм күрсәтә;

Фондның Попечительләр советы әгъзаларының тавышларын санауны алып бара;

Фондның Попечительләр советы утырышлары беркетмәләрен һәм Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне алып бара һәм тутыра;

Фондның Попечительләр советы утырышлары беркетмәләреннән, Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдән өземтәләр ясый һәм аларны үз имзасы белән раслый;

Фондның Попечительләр советына килгән документларны һәм аннан җибәрелгән документларның күчермәләрен исәптә тотуны, саклауны башкара.

6.45. Фондның башкарма директоры Фонд төзелгәндә беренче тапкыр Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләп куела. Алга таба Фондның башкарма директорын вазыйфага билгеләп куюны һәм аны вазыйфадан азат итүне Фондның Күзәтчелек советы башкара.

Фондның башкарма директорының вәкаләтләре – 5 (биш) ел.

6.46. Фондның Башкарма директоры белән хезмәт шартнамәсен төзүне, үзгәртүне, аның гамәлен туктатуны Россия Федерациясе законнары нигезендә Фонд исеменнән Гамәлгә куючы башкара.

6.47. Фондның Башкарма директоры:

Фонд исеменнән ышаныч язуыннан башка гына гамәл кыла, барлык оешмаларда, дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында Фондның мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә;

Фонд исеменнән үз вәкаләтләре чикләрендә шартнамәләр төзи, ышанычнамәләр бирә;

кредит оешмаларында хисап счетлары һәм башка счетлар ача;

Фондның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрне раслый;

Фондның штат расписаниесен раслый, законнар нигезендә хезмәткәрләр яллый һәм аларны эштән җибәрә, алар арасында йөкләмәләрне бүлә;

Фондның Күзәтчелек советы раслаган смета чикләрендә Фондның мөлкәтен һәм акчасын тотуны Фонд эшчәнлегенең максатлары, Фондның Күзәтчелек советы карарлары һәм Фондның Попечительләр советы карарлары нигезендә катгый төстә билгеләнешенә карап башкара;

үз вәкаләтләре чикләрендә Фонд хезмәткәрләре үтәргә тиешле боерыклар чыгара һәм күрсәтмәләр бирә;

Фондның Күзәтчелек советы һәм Фондның Попечительләр советы карарларын үтәүне тәэмин итә;

Фондның Күзәтчелек советы утырышлары арасында үз вәкаләтләре чикләрендә Фондның эшчәнлеге мәсьәләләрен хәл итә;

хисап бирүне һәм хисаплылыкны алып баруны оештыра, Фонд мөлкәтеннән файдалану турында хисапны ел саен бастырып чыгаруны тәэмин итә;

Фондның Күзәтчелек советына Фонд эшчәнлегенең йомгаклары турында хисап бирә;

Фондның Күзәтчелек советы белән килештереп Фондка идарә итү буенча Фондның башка органнары вәкаләтләренә карамаган эшчәнлекне башкара.

6.48. Фондның финанс-хуҗалык эшчәнлеген Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) контрольдә тота.

Фонд төзелгәндә беренче тапкыр Фондның Ревизия комиссиясе әгъзалары (ревизор) Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләп куела. Алга таба Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) Фондның Күзәтчелек советы тарафыннан сайлап (билгеләп) куела.

Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) вәкаләтләре срогы – 5 ел.

6.49. Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) Фондның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә ел саен тикшерү уздыра.

Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) эшенең тәртибе Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) турында нигезләмәдә билгеләнә.

6.50. Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) Фондның вазыйфаи затларыннан барлык кирәкле документларны һәм шәхсән аңлатмалар бирүне таләп итәргә хокуклы.

6.51. Фондның Ревизия комиссиясе (ревизор) елга кимендә бер тапкыр Фондның Күзәтчелек советына һәм Фондның Попечительләр советына тикшерүләр йомгакларын тапшыра.

## VII. Хисап һәм контроль

7.1. Фонд бухгалтерлык хисабы алып бара, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык (финанс) һәм статистика хисабы ясый һәм тапшыра.

7.2. Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә үз эшчәнлеге турындагы мәгълүматны дәүләт статистикасы, салым органнарына, Гамәлгә куючыга һәм башка затларга тапшыра.

7.3. Фонд үз мөлкәтеннән файдалану турында хисапны ел саен бастырып чыгара.

7.4. Фондтагы бухгалтерлык хисабын оештыру, аның торышы һәм дөреслеге, тиешле органнарга еллык хисапның һәм финанс белән бәйле башка хисапларының, шулай ук Фонд эшчәнлеге турында Фонд бирә торган мәгълүматларның үз вакытында тапшырылуы өчен җаваплылык Фондның башкарма директорына йөкләнә.

7.5. Фонд түбәндәге документларны саклый:

Фондның тиешле тәртиптә теркәлгән Уставы һәм аңа үзгәрешләр кертү турында карарлар, шулай ук Фондны төзү турындагы карар;

Фондның дәүләт теркәве узуы турындагы документ;

Фондның үз балансындагы мөлкәтенә хокукларын раслый торган документлар;

Фондның филиаллары һәм вәкиллекләре турында нигезләмәләр;

еллык хисаплар;

бухгалтерлык исәбе һәм хисабы документлары;

Фондның Күзәтчелек советы һәм Фондның Попечительләр советы утырышлары беркетмәләре, Фондның Күзәтчелек советы һәм Фондның Попечительләр советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирү йомгаклары беркетмәләре;

Фонд аудиторының, Фондның Ревизия комиссиясенең (ревизорның), башка контроль органнарының бәяләмәләре;

федераль законнарда каралган башка документлар.

7.6. Еллык финанс хисабының дөреслеген тикшерү һәм раслау өчен Фонд үзенең мөлкәти мәнфәгатьләре белән бәйләнмәгән профессиональ аудитор ялларга мөмкин. Аудиторның Фондның эшчәнлеген тикшерүе Гамәлгә куючы, Фондның Күзәтчелек советы, Фондның Попечительләр советы таләбе буенча теләсә кайсы вакытта уздырылырга мөмкин.

## VIII. Фондның Уставына үзгәрешләр кертү тәртибе

8.1. Фондның Уставына кертелә торган үзгәрешләр Фондның Күзәтчелек советы тарафыннан раслана.

8.2. Фондның Уставына үзгәрешләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлергә тиеш.

## IX. Фонды бетерү

9.1. Фонды бетерү Россия Федерациясе законнарында каралган нигездә һәм тәртиптә башкарыла.

9.2. Фонды бетергәндә кредиторларның таләпләрен үтәгәннән соң калган мөлкәт Фондның төзелүе аларны канәгатьләндерү белән бәйле булган максатларга һәм (яки) хәйрия максатларына юнәлдерелә. Әгәр гамәлгә кую документлары нигезендә Фондның мөлкәтен файдалану мөмкин булмаса, ул Татарстан Республикасы кеременә әйләнә.

9.3. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тиешенчә язып куелганнан соң Фонды бетерү эше тәгәлләнгән, ә Фонд ябылган дип санала.

_______________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «03» февралендәге
ПУ-85 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Игелек-Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондының Күзәтчелек советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Күзәтчелек советы рәисе |
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары |
| Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гәрәев Зөфәр Фәнил улы | «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарә рәисе (килешү буенча) |
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Когогин Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сәлахов<br>Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сорокин<br>Валерий Юрьевич | «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Усманов<br>Рөстәм Ринат улы | «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәрдиев<br>Илшат Шәех улы | «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шәйхразиев<br>Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Шиһабетдинов<br>Альберт Кашаф улы | «ТАИФ» идарәче компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

_____________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «_03_» _феврალендәге_
ПУ-_85_ номерлы Указына
3 нче кушымта

**«Игелек-Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондының Попечительләр советы составы**

| | |
|---|---|
| Әхмәтов<br>Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Попечительлек советы рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиева<br>Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Зәйдуллин Ркаил<br>Рафаил улы | Татарстан Республикасы халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Нугаев<br>Камил Әсгать улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Харисов<br>Ренат Мәгъсүм улы | Татарстан Республикасы халык шагыйре, Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |